Гарифҗан Мөхәммәтшин

Серләвек



Гарифҗан Мөхәммәтшин

Серләвек

ШИГЫРЬЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1999

ББК 84 (Р-Тат)-5
М 98

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына

Ирина Антонова рәсемнәре

Мөхәммәтшин Гарифҗан

М 98 Серләвек: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 48 бит.

Җыентыкка урнаштырылган шигырьләр балаларны тирә-юньгә, табигатькә игътибарлы һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Аларда балалар тормышы ачык, җете төсләрдә, җанлы итеп сурәтләнә.

ISBN 5—89120—031—7

© Татарстан китап нәшрияты, 1999



СЕРЛӘВЕК

Челтер-челтер, челтер-челтер,
Ни сөйли бу гөрләвек?
Тыңлап торсаң — бер могҗиза,
Бу гөрләвек — серләвек!

●

ТАНЫШ СУКМАК

Бу сукмакларның тузаны
Һаман да кайнар микән?
Яланаяк бассам әгәр
Эзләрем калыр микән?
Үр башындагы карама
Үземне таныр микән?
Элеккечә, яулык болгап,
Озатып калыр микән?..

КУЯН

(Мәсәл)

Очраткач Тычканны юлында
Кычкырган:
　　　　— Кит юлдан!
Очрагач Бүрегә
　　　　үзе үк
Шып кына юлыннан
　　　　юк булган.

ТУГАН АВЫЛ

Безнең авыл чишмәле,
Борма-борма инешле,
Безнең авыл бакчалы,
Татлы-тәмле җимешле,
Җырга салып җырлап була —
Исеме дә килешле.

Инеш буйлап — болыны,
Болын тулы гөлләре;
Гел тулы болыны нәкъ тә
Әбиемнең күлмәге!

Каршысында таулары,
Тауларында урманы...
Йә әйтегез, кемнең бар
Шул авылда булганы?
Ничек аның исеме?
— Белдем, белдем! — дисеңме?

Аңладым белгәнеңне,
Болынында йөргәнеңне,
Суында йөзгәнеңне,
Җимешен өзгәнеңне...
Ул — минем туган авыл,
Ул — синең туган авыл,
Үзең туган авыл гына
Шулай матур була ул!

БЕЗНЕҢ ИНЕШ

Безнең инеш бик кечкенә —
Исеме дә юк аның.
Әмма күрсәң
шул инештә
Талларның юынганын,
Сандугачлар сайраганын,
Таллары саен кунып...
Китәсең
шушы инешкә
Гомерлек гашыйк булып!
Кечкенә булганга аңа
Беркем исем кушмаган,
Тыйнак кына ага-ага,
Кушыла ул Шушмага.
Шушма Нократ, Кама аша
Барып җитә Иделгә —
Димәк, аның сулары да
Иделкәйнең иңендә!
Кем әйтер безнең инешне:
«Бик кечкенә!» — имеш, ул...
Үз әнисе Иделкәйгә
Көч өстәгән Инеш ул!

ҖЫРЛА, МУСА!

Нәни җырчы Муса Маликовка

Җырла әле, җырла, Муса,
Нәкъ безнеңчә — татарча,
Халык җыры моңсу була,
Җаны хаксыз тапталса.
        Нәкъ безнеңчә моңсу итеп,
        Яңгыратып җырла, Муса,
        Газабын моң итә халык,
        Бәгырендә җәбер буса.
Яшә, моңлы татар җыры,
Моңнарыңнан суынма,
Илт, Муса, халкыбыз җырын
Буыннардан-буынга.
        Заман җиле бер киерер
        Җаннарның ак җилкәнен;
        Син аңлыйсың микән әле
        Моңның нәрсә икәнен?
Моң ул ерак бабайларның
Васыяте безнең чорга,
Онытылмасын ул васыять,—
Өздереп-өзеп җырла!
        Өзелмәс халык хәтере,
        Шушы моңнар тынмаса;
        Халык җаны тын калалмас,
        Синең җырны тыңласа.
Уятыр моң халык җанын,
Күр син, туа яңа көн,
Яңа көнгә мәдхия ит —
Әссәламәгаләйкем, әссәламәгаләйкем!

КҮҢЕЛСЕЗ КӨН

Ашавы татлы түгел,
Көне дә якты түгел,
Килә елыйсы гына —
Ничек чыдыйсы менә?

Ни булган соң бу таңга?
Нәрсә булган Чулпанга?
Юньләп күзе ачылмый,
Йокысы да басылмый.
Күп калмаган төшкә дә,
Кул бармый бер эшкә дә...

Беләсезме ни булган?
Торгач бүген йокыдан,
Әллә нигә Таңчулпан
Бит юарга оныткан.

ХЫЯЛ

Тар инештә
Кораб йөзә,
Алга таба
Карап йөзә.

Агач кораб,
Кәгазь җилкән,
Җитез җилне
Кораб җиккән.

Кая йөзә
Икән кораб,
Дулкыннарны
Ярып-тарап?..

Уйчан малай
Ярга баскан,
Суга карап
Уйга баткан.

Карашлары —
Дулкыннарда,
Ә күңеле —
Океаннарда.

Кысып тотып
Штурвалны,
Дулкын яра,
Тугыз баллы.

ТУГАН КӨН

Көз булса да җылы бүген,
Болытлар да качканнар,
Кояшның назлы нурлары
Бар дөньяны кочканнар.
　　Өебез дә әллә нигә
　　Кичәгедән ямьлерәк,
　　Әни пешергән ашлар да
　　Кичәгедән тәмлерәк.
Укытучы апабыз да
Күбрәк куйды бишлене,
Әллә инде кесәсендә
Бишлеләре ишләме?
　　Бүген бар да башкачарак,
　　Назлырак һәм яктырак.
　　Нинди көн соң бүген? — диеп
　　Калмагыз ла аптырап.
Бүген бездә зур бәйрәм көн —
Ләйсәннең туган көне,
Бик тә зур булган көне,
Гел көлеп торган көне!

ТУП

Сикерә туп:
— Тып, тып, тып.
Йөгерә туп:
— Тот, тот, тот!
Йомры булгач,
тик тормый;
Машинага
утырмый.
Җәяү чаба,
тоттырмый.

ДУМБРА

Ыңгырашып, сыкрый, елый
Думбраның кыллары,
Агыла моң, тыңлый дала,
Тыңлый дала кылганы.

Кыл өстендә, ярсый-ярсый,
Моң эзлиләр бармаклар,
Әйтерсең лә дала иңләп
Чабыша аргамаклар.

Кылларга төбәлгән күзләр
Якты, ярсу, сагышлы.
Шул күзләрдә чагыла моң —
Ерак еллар тавышы.
Агыла моң...

ӘНИ БӘЙЛӘГӘН ОЕКБАШ

Ары чаба, бире чаба —
Йомгак йөри тәгәрәп;
Ничек тәгәрәмәсен, ди —
Йомгак бит ул түгәрәк.

Тәгәрәтеп зур йомгакны,
Әни бәйли оекбаш;
Әни бәйләгән оекбаш
Ничек инде җылытмас!

БАБАЕМНЫҢ БАЛТАСЫ

Бабаемның балтасы
Останың иң остасы —
Эшләмәгән эше юк,
Сокланмаган кеше юк.

Бура бурый ала ул,
Кирәксә өй сала ул
Чуарлап кәрнизләрен,
Бизәкләп тәрәзләрен.

Үзе дә әйтә бабай:
— Ну минем балта, малай!
Балта гына түгел, — ди, —
Минем кулым күк ул, — ди.

Тыңлыйм да бабайны, уйлыйм:
Алаен ул алай да,
Оста, диеп кешеләр соң
Ник әйтәләр бабайга?!



СӘГАТЬ

Тормый ул бер дә туктап,
Берөзлексез «тик» та «так».
Уңга атлыйм берне, ди,
Сулга атлыйм берне, ди,
Бервакытта да туктамам
Күтәрсәгез герне, ди.

Тәүлек буе эштә мин,
Тик арымыйм һич тә мин.
Берне атлыйм сулга, ди,
Берне атлыйм уңга, ди,
Минем белән дус булсагыз
Калмассыз һич соңга, ди.

Йокыдан торырга да,
Шәпләп юынырга да,
Зарядка ясарга да,
Бик тәмләп ашарга да,
Мәктәпкә барырга да,
Ял итеп алырга да...

Берөзлексез «тик» та «так»,
Йөри ул, тормый туктап.
Берне атлыйм уңга, ди,
Берне атлыйм сулга, ди,
Вакытның кадерен белегез,
Бәхет әнә шунда, ди.

ТАПСЫЗ КИТАПЛАР

Китапларыбыз күп безнең —
Рәт-рәт тезелеп тора;
Шкафыбыз киштәләре
Хәтта бөгелеп тора.

Тик укырга ярамый шул
Безгә ул китапларны, —
Укыганда аларга бит
Төшә бармак таплары.

Әти әйтә: «Китапларга
Якын да килмәгез!» — ди.
Әниебез: «Каралтырсыз,
Кул да тидермәгез!» — ди.

Китапларыбыз күп безнең
Чип-чиста, тапсыз гына.
Үзебез китап арасында,
Ләкин... китапсыз гына.

●

УРМАН

Усаклар, бөгелә-сыгыла,
Лепердәп сөйләшә җил белән;
Кочарга теләгән шикелле,
Наратлар кояшка үрелгән.

Гасырлар чордашы карт имән
Арыган, басынкы тавышлы;
Әйтерсең сөйли ул үзенең
Башыннан кичергән тарихны.

Каеннар, тузгытып, чәчләрен
Карама иңенә салганнар;
Хозурлык юрганын ябынып,
Юкәләр йокыга талганнар.

Бер кәккүк кычкырды өч кабат:
— Озак яшә, — дип теләк теләде.
Теләген куәтләп кәккүкнең,
Сандугач җыр башлап җибәрде.

Сихри дә, шомлы да бер моңга
Чумган да, ухылдый бар урман;
Күңелне сыкратып
                    кайдадыр
Ишетелә моңлы җыр «Карурман».

●

ЮГАЛГАН ЙОМГАК

Шаян минем пескәем —
Тик торганы юк аның;
Иш иттергән үзенә
Әбекәйнең йомгагын.

Әй яратты ул аны —
Тәгәрәтеп уйнады,
Күп уйнады, туймады:
Әрле-бирле китерде,
Тәмам сүтеп бетерде.

Юкка чыккач йомгагы,
Эзләп йөрде арганчы,
Эзләп йөрде арганчы,
Арып хәлдән тайганчы.

Шулай ерак качкан өчен
Үпкәләде йомгакка,
Йомгак кебек йомарланып,
Йоклап китте почмакта.

КӨНБАГЫШЛАР

Сары читле эшләпәне
Кырын салып,
Утыралар көнбагышлар,
Уйга калып.

Бу уйчанлык аларга соң
Килгән кайдан?
Шуңа уйчан көнбагышлар,—
Кояш баеган...

Кемгә карап мутлансыннар
Хәзер алар?
Таңга кадәр шулай моңсу
Калыр алар.

ТАМЧЫ

Тамды тамчы зур диңгезгә —
Диңгез йотты,
Тамды тамчы салкын ташка —
Юкка чыкты.

Кунды тамчы гөл чәчәге
Керфегенә —
Әверелде гүя энҗе
Бөртегенә!

●

ЯҢГЫР АЛДЫННАН

Күктә тургай, җирдә яшел
Уҗымнар чәбәләнә,
Яшен утын атар өчен
Күк болыт җәяләнә.

Гөл куенына тамар өчен
Тулып килә тамчылар,
Бер мизгелдән җир аркасын
Чажлап яңгыр камчылар.

Яу әйдә, яу, ләйсән яңгыр,
Дөнья синнән җим көтә,
Яшәрү, сафлану хисе
Җирне шулай җилкетә.

УМЫРЗАЯЛАР

Карны тишеп чыккан алар,
Нинди чаялар, —
Чәчәк аткан, чәчәк аткан
Умырзаялар!

Шушы чәчәкләрдә кебек
Җирнең бар яме,
Язның әле башы гына,
Алда дәвамы.

Чәчәкләр әле күп үсәр
Алда — җәйләр бар,
Күңелдә тик сулмый балкыр
Умырзаялар.

ТАҢЧЫЛАР

Таң атуга
                өй артында
Бии башлый тамчылар.
Әй тамчылар, тамчылар,
Сез, мөгаен, таңчылар!

АК ДУЛКЫННАР

Ак көймәсе йөзеп үтте,
Ак дулкыннар калдырып —
Шаян якты йолдызларны
Тибрәтеп, чайкалдырып.

Алар, уйнап, бер-берсенә
Кысыштылар күзләрен;
Кояш чыкса, берәм-берәм
Чүпләр әле үзләрен!

●

ШАР КАБАРТАМ

Бик тырышып өрәм-өрәм,
Шар кабартам бирәм-бирәм:
Бусы кызыл, бусы яшел,
Бусы сары, бусы көрән.
Минем бик тырышканымны
Акбай да күреп тора,
Бик тә булышырга теләп,
Туктаусыз өреп тора:
— Һай-һау-һау...
Икебез дә өрәбез —
Шар кабарта беләбез!



БОЛЫН

Бизәкләрнең күплеге,
Төсләрнең назлылыгы, —
Бу болыннар гүя минем
Әбкәмнең намазлыгы!

ЯЗ

Язлар инде җитте дәмени?..
Тәүге тамчы түбә кыегыннан
Ап-ак карга төште егылып.
Гөрләвекләр купты. Инеш, ташып,
Ярларыннан чыкты ургылып.

Тәүге тургай күккә күтәрелде,
Җирдә тәүге үлән күренде.
Тәүге бөре, ярысын салып ташлап,
Яфрак булып күккә үрелде.
Язлар инде үтте дәмени...

КОЯШ БАЕГАНДА

Офыктагы карамага
Кунып ял итте кояш.
Ял итте дә
　　　　тау артына
Тәгәрәп китте кояш...

КҮЛДӘ

Әй киләә соң бакаларның
Үзләрен мактатасы, —
Төне буе тынмый күлдә
Бакалар кантатасы.

ТАМЧЫ ҺӘМ ЧЫПЧЫК

Күлләвеккә егылып төшеп
Бата язды бер тамчы;
Ярый итәгеннән чыпчык
Тартып алды
　　　　батканчы...

ТАҢ НУРЫ

Ал таң нуры су коена
Инештә,
Таң нурына су коену
Килешә.
Чумып китә су төбенә —
Тирәнгә,
Калкып чыга аннан ул "эһ!"
Дигәндә.
Дулкыннардан дулкыннарга
Сикерә.
Йөзә, чума таң балкышы,
Су керә...
Шулай көн дә су кергәнгә
Таң нуры,
Якты, аяз була җәйнең
Таңнары.

ДУЛКЫННАРДА САРЫ ЯФРАК

Мәрхәмәтсез көзге җилләр
Усакларны бөгеп талый;
Яп-ялангач калдырган ул
Инеш күрке — бөдрә талны.

Каз бәбкәседәй, яфраклар
Уйнап ага дулкыннарда.
Яп-ялангач калган таллар
Нишләр кышкы салкыннарда?

КӨЗГЕ ВАЛЬС

Саргайган каен,
Саргайган имән,
Бушанган кырлар,
Корыган үлән.
Әкрен шыбырдап,
Яфрак коела;
Җир әкият сөйли
Кебек тоела —
Ямь-яшел, ямьле
Язлар турында,
Тезелеп кайткан
Казлар турында,
Чәчәкле, матур
Җәйләр турында,
Җәйдәге садә
Ямьнәр турында,
Һәм сары, салкын
Көзләр турында...
Өзелә әкият
Шушы урында.
Көзге җил
вальс
Уйнап җибәрә,
Бии яфраклар,
Күреп җилләрдән.
Бииләр алар
Соңгы вальсны —
Көзге вальсны,
Моңлы вальсны...

СЕНТЯБРЬ

Җәй белән көз кавышкан чак —
Бераз бөркү, бераз салкын,
Усакларда чуар яулык
Һәм чулпылар — бары да алтын!

Алтын чулпылар җырыннан
Моңсу тынлык зыңлап тора;
Көзге урман, тып-тын калып,
Шушы зыңны тыңлап тора.

КӨЗГЕ ЭТЮД

Урман буйларына тезелешкән
Каен, юкә, усак, өрәңге;
Нинди генә күлмәк кимәгәннәр —
Сарысы бар, кызыл, көрәне.

Парадтагы кебек ясанганнар,
Ярышып пөхтәлектә, төзлектә.
Чуар келәм җәйгән юллар буйлап
Парад кабул итеп, көз үтә.

●

ФӘРИТ БЕЛӘН ФИЗЗАРЯДКА

Радио физзарядка ясый,
Бөтен шартын китереп:
Башта ала йөгереп,
Аннан китә сикереп.
Уңга-сулга атына,
Бөгелә ул уртына;
Сөртә-сөртә тирләрен
Уйната зур герләрен...
Фәрит юрган астында
Ята тымызык кына,
«Ай-һай булдыра бу!» — диеп,
Көнләп-кызыгып кына.
Ә нигә соң үзе торып
Физзарядка ясамый?
Ясар иде дә бик тә,
Ялкаулыгын басалмый!

ЧЫРШЫЛАР НИК КҮҢЕЛСЕЗ?

Таулар чумган ак томанга,
Гүя шәл ябынганнар.
Усаклы тау урманнары
Ялкыннан кабынганнар.

Йолкып-йолкып, усакларның
Яфракларын саный көз.
Чыршыларга көзләр тими, —
Алар шуңа күңелсез.

МИЛӘШЕМ

Челтәрле шәлен бөркәнеп,
Зифа буйлы миләшем,
Яулык итеп, кемгә шулай
Болгый икән тәлгәшен?

Ямьле җәйне, өзгәләнеп,
Шулай озата микән?
Үреләүреләү, килер язны
Әллә күзәтә микән?..

ЯҢА ЕЛГА МОҢСУ ШИГЫРЬ

Чыршылар кайта урманнан
Яңа ел бәйрәменә —
Клубка, өйгә, мәктәпкә
Һәм шәһәр мәйданына.

Кайта чыршының зурлары,
Кайта кечкенәләре;
Синтетик чыршыларга без
Карыйбызмы соң хәзер...

Кайта алар машинада,
Кайта алар чанада...
Бер бәйрәмгә ничә чыршы
Корбан була, чамала!

— Чамалавы кыен түгел,
Болай булса, — ди күңел, —
Чыршыларны төштә генә
Күрер көн ерак түгел.

АК БОЛЫТЛАР ЙӨЗЕП БАРА

Ак болытлар йөзеп бара,
Йокымсырап, оеп;
Әйтерсең лә аккош үткән,
Каурыйларын коеп...

Очыгыз, оч, ак болытлар,
Кыйблаларга табан,
Аккошлар булып кайтыгыз, —
Язлар көтеп калам!

ШАЯН ЭТЮД

Ай көймәсе йөзеп үтте,
Ак дулкыннар калдырып,
Шаян, якты йолдызларны
Тибрәтеп, чайкалдырып.

Алар, уйнап, бер-беренә
Кысыштылар күзләрен,
Кояш чыкса, берәм-берәм
Чүпләр әле үзләрен!

АПРЕЛЬ КОЯШЫ

Үкси-үкси елый апрель кары,
Тамчы булып тама түбәдән,
Төш җиткәндә
апрель кояшында
Эреп бетә, хәтта, күләгәң!..

Тамчыларны җыеп агымына,
Гөрли башлый язгы гөрләвек;
Гөрләвекләр җырлап кушыла да
Пәйда була күзге-күлләвек.

Күлләвеккә төшеп, чыркылдашып,
Су керенә чыпчык кызлары.
Чыпчыкларга кушылып, көлә-көлә
Эреп китә апрель бозлары.

Һәр тарафта якты яз балкышы,
Һәр тарафта якты яз гаме;
Кояш кебек гел көләсе килә,
Елмаясы килә...
— Язгамы?..

БӘХӘС

Шундый кызык
ай ул март —
Бер кырыс ул,
бер юмарт.

Кояшы — ис
китәрлек,
Салкыны да
җитәрлек.

Кышның килми
китәсе,
Язның килми
Көтәсе.

Мәш килеп бил
алыша —
Кыш белән яз
ярыша.

Март артында,
күз кысып,
Апрель тора,
посып...

— Тиздән килеп
җитәм, — ди, —
Бәхәсне хәл
итәм, — ди.

КОМАНДИР БАРЫЙ

Класс җыештыра малайлар,
Барый йөри иң алдан.
Боерык бирергә Барый
Ким түгел генералдан.

— Рөстәм, син өстәлләрне сөрт!
— Фәнис, син суга йөгер!
— Ләйсән, тәрәзә юарсың,
— Марат, син идән себер!

— Туктале, үзеңә бер дә
Эш калмады бит, Барый.
— Мин бит саран кеше түгел,
Миңа шулай да ярый!

ГАРИФМЕТИКА

— Ике икең ничә, Гариф?
— Дүрт була.
— Ә биш бишең ничә була?
— ...Күп була!

КАЯ КИТКӘН?

— Улым, нигә әле болай
Самолетыңны ваттың?
— Сүтеп бетердем бар җирен,
Очучысын һич тапмыйм!

●

ТАБЫШМАК

Җиде катлы күпер салдым
Җиде күкнең чатында,
Дөбер-дөбер кемдер үтте
Көмеш яллы атында.

(Салават күпере,
яңгыр, күкрәү.)

ИКЕ МАКТАНЧЫК

— Бүген, малай, балык тоттым,
Менә моны-ы-ы-ң кадәр!
— Ә мин тоттым кичә берне,
Менә сине-е-е-ң кадәр!

●

ИКЕЛЕГӘ УКУЧЫ МАЛАЙ ХЫЯЛЫ

Вәт күрерсез, килер бер көн,
Алып махсус хисапка,
Сакларсыз әле сез безне,
Язып «Кызыл китап»ка!

АЧКЫЧ

Үзе кечкенә булса да,
Ачкычта икән белем, —
Белә беркем белми торган
Баш кадәр йозак телен.

●

ЕЛАК

Уйнаганда ялгышып
Егылган беркөн Барый.
(Ара-тирә малайларга
Егылсалар да ярый.
Егылудан нәрсә була,
Торасың да китәсең.
Егылуның файдасы бар —
Таза булып үсәсең!)
Барый моны белмәгән,
Яшь аралаш көлмәгән,
Ә тотынган еларга.
(Йә, ни дисең моңарга!)
Китми икән һич торып,

Елый икән кычкырып.
Иптәшләре Барыйны
Юатып караганнар,
Иптәшләре Барыйны
Оялтып караганнар,
Булышып караганнар,
Орышып караганнар —
Барый гел тормый икән,
Барый гел елый икән...
Аптырагач дуслары,
Бу гаҗәп хәлне күреп,
Әйткәннәр, ди, Барыйга:
«Елак син кызлар кебек!»
Ә бер читтә чыркылдашып
Торганнар кызлар көлеп.

АҢЛАМАССЫҢ

Кара карга
Төште карга,
Сикергәли
Ап-ак карда.

Очып китте
Карга үзе,
Челтәр-челтәр
Калды эзе.

Кара карга
Кара иде,
Эзләре ак —
Кара инде!

Кара карга
Үткәч, ничек
Ап-ак эзләр
Кала төшеп?

Бу дөньяны
Аңламассың!
Сорыйк мәллә
Каргадан соң?

ОРЧЫК

Әйләнә орчык, әйләнә,
Әйтерсең лә биюче;
Юк аңа бары, кул чабып:
«Булдырасың!» — диюче.

Мактаганны көтеп тормый,
Уйламый да туктарга —
Ничек инде, орчык булып,
Карап торсын юк-барга!

Әйләнә дә биеп китә,
Аннан сикереп куя;
Хәтта очып китәр иде,—
Әнкәйнең кулын тоя.

Мин сокланып карап торам,
«Ай-һай җитез бу!» — диеп;
Юкка әйтми икән әти:
«Орчык кебек бул!» — диеп.

ТӘГӘРМӘЧЛӘР СУСАГАН

Тәгәрмәчләр сусаган,
Кигиләре бушаган.
Су сорыйлар ялварып:
— Су, су, — диләр, зарланып.

Коендырдык арбаны,
Коры җире калмады.

Сөенделәр тәгәрмәчләр,
Кайталар келтер-келтер;
Хәерле юл теләп калды
Чишмәләр челтер-челтер.

АКЫЛСЫЗ ҖИЛ

Күпме хикмәт кышта —
Буран уйный тышта,
Ак кар ява уйнап,
Җилләр дөнья буйлап
Сызгырышып йөри,
Себеркесез генә
Урамнан кар көри.
Ә капка төбенә
Өя шул ук карны,
Йә, әйтегез инде,
Җилнең акылы бармы?

КЕМ КЕМГӘ ТИГӘН?

Уйнамый да, көлми дә —
Нәрсә булган Барыйга?
Доктор килеп карый да:
— Салкын тигән сиңа, —ди,—
Сакланмадың нигә? —ди.

Күзен ачып, көч-хәл белән
Уйлый Барый эчтән генә:
«Доктор берни белмәде, —ди,—
Салкын миңа тимәде, —ди.—

Ул килмәде якын да, —ди,—
Үзем тидем салкынга! —ди.—

Шундый кәмит ясадым мин,
Хоккейдан соң салкын карны
Учлап-учлап ашадым мин!

Шулай булгач, уйлагыз, —ди,—
Кем соң кемгә тигән була?
Берни белми икән доктор,
Салкын тигән, дигән була!»

ҮРДӘК ҺӘМ БАКА

Үрдәк — дошман бакаларга,
Моны күптән белә һәркем,
Бакаларның газиз башын
Кисеп тора мәлгунь һәр көн.

Түзә алмый мондый хәлгә
Берәр чара табарга дип,
Һичьюгында үрдәкләрне
Бер үгетләп карарга дип.

Уйлаган да сасы күлдә
Тыныч кына ята-ята,
Үрдәк телен өйрәнергә
Карар кылган, ди, бер бака.

Тотынган ул кычкырырга
Үрдәк телен җимерә-вата:
Бак-бак, бак-бак, ба-ка-ка-ка,
Бак-бак, бак-бак, ба-ка-ка-ка...

Күп тә үтми, шул тавыштан
Аны үрдәк эзләп тапкан;
Эләктереп аягыннан,
Күз йомганчы кабып йоткан.

Бу мәсәлне укып чыккач
Ал үзеңә шундый сабак
(Юкса, яңа түгел үзе,
Әйтелгәндер ничә кабат):

Дошманыңның телен өйрән,
Тик шунда бер нәүбәтендә
Онытма син өйрәнергә
Аның кайбер гадәтен дә!

БАУ ҺӘМ ҖЕП

(Мәсәл)

Бау көлгән Җептән:
— Син нинди нечкә.
Бер килоны да
Тотасың көчкә.

Син миңа кара,
Мин нинди таза.
Миңа йөкләрнең
Барсы да бара.

— Әйе, — дигән Җеп,
— Син, Бау, таза бик,
Әмма минем күк
Меңләгән Җептән
Син үрелгән бит!

Тәрбия эзләп,
Укыма кабат;
Мактана күрмә,
Үзеңә карап!

ЭЧТӘЛЕК

Серләвек 3
Таныш сукмак 4
Куян 4
Туган авыл 5
Безнең инеш 6
Җырла, Муса! 7
Күңелсез көн 8
Хыял 9
Туган көн 10
Туп 11
Думбра 12
Әни бәйләгән оекбаш 12
Бабаемның балтасы 13
Сәгать 14
Тапсыз китаплар 15
Урман 16
Югалган йомгак 17
Көнбагышлар 18
Тамчы 18
Яңгыр алдыннан 19
Умырзаялар 19
Таңчылар 20
Ак дулкыннар 20
Шар кабартам 21
Болын 22
Яз 22
Кояш баеганда 23
Күлдә 23
Тамчы һәм чыпчык 23
Таң нуры 24
Дулкыннарда сары яфрак 24
Көзге вальс 25